**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**09.02.2018** **№ 369**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының өстәмә белем бирү муниципаль оешмаларында бюджеттан тыш акчалар җәлеп итү турында» 2016 елның 07 ноябрендәге 2317 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон (2012 елның 10 июлендәге редакциясендә), «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында», Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 12 декабрендәге 597 номерлы (2014 елның 13 февралендәге 85 номерлы редакциядә) карары нигезендә һәм өстәмә белем бирү муниципаль оешмаларының бюджет финанславын чигерүгә факттагы чыгымнарын каплауны тәэмин итү, өстәмә белем бирү муниципаль оешмаларының матди-техник базасын үстерү һәм ныгыту максатында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 07 ноябрендәге 2317 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы өстәмә белем бирү муниципаль оешмаларында бюджеттан тыш акчаларны җәлеп итү турында» 2016 елның 23 декабрендәге 2760 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 5 пунктта түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

- җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән 100 % күләмендә кимрәк булган аз керемле гаиләләрдән булган балаларга.

1.2 Түбәндәге эчтәлектәге 5.1 пункт белән тулыландырырга:

«5.1. Биектау муниципаль районындагы РЦМП №17 бүлегенә хисап тапшыруыннан соң килә торган айның 25 числосына кадәр ай саен "Балкыш" ДДТ

МАУДО, Биектау муниципаль районы башкарма комитетының Мәдәният бүлегенә, Биектау муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр һәм спорт бүлегенә Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбәнрәк җан башына уртача керемле гаиләләр арасыннан айлык пособие билгеләнгән балалар турында мәгълүмат бирергә тәкъдим итәргә».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Ф. Хөснетдинов